“Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф идарәсе” муниципаль казна учреждениесе
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасы
“Азнакай шәһәре балалар иҗат үзәге”

Педагогик совет утырышында
каралды һәм кабул ителде
Беркетмә №_1_____
“_07_” __09____ 2022ел.

ГАМӘЛГӘ КЕРТЕЛДЕ
_07.09.2022_ приказ №_126_
Директор: ӨББМБО “Азнакай шәһәре БИҮ”
_________ Р.М Хасанова

“_07_” _09. 2022_____ел.

# "Күңелле татар теле"өстәмә гомуми белем бирү, гомумүсеш программасы

Юнәлеш: табигый-фәнни
Укучыларның яше: 11 -17 яшьлекләр өчен
Гамәлгә ашыру вакыты: 1 ел (144 сәгать)

Автор-төзүче:
Фазлыева Гөлфинә Нашат кызы,
өстәмә белем бирү педагогы

Азнакай шәһәре, 2022

Эчтәлек

1.Аңлатма язуы_________________________________________3-8 бит

2.Уку-укыту тематик планы____________________________________8 бит

3.Программаның эчтәлеге______________________________________9 бит

4. Планлаштырылган нәтиҗәләр_________________________________10 бит

5. Программаны тормышка ашыруның оештыру-педагогик шартлары
______________________________________________________________ 12 бит

6. Аттестацияләү формалары/контроль һәм бәяләү материаллары -10 бит

7.Әдәбият исемлеге_____________________________________________15 бит

## 1 нче бүлек

## Аңлатма язуы

“Күңелле татар теле” өстәмә гомуми белем бирү**, гомумүсеш программасы** түбәндәге норматив-хокукый документларга нигезләнеп төзелде :

1. "Россия Федерациясендә Мәгариф турында" 29.12.2012 чыккан № 273 - ФЗ Федераль законы;

2. Балаларга өстәмә белем бирү үсеш концепциясе (4 нче сентябрь 2014 нче елда чыккан, № 1726-р РФ Хөкүмәте карары );

3. “Мәгариф” милли проекты кысаларында “Һәр баланың уңышы” федераль проекты РФ Президенты каршындагы Стратегик үсеш һәм милли проектлар советы президиумның 2018 елның 3 сентябрендә 10 номерлы утырыш беркетмәсе белән расланган.

4. Россия Мәгариф министрлыгының “Балаларга өстәмә белем бирүнең төбәк системаларын үстерүнең максатчан моделен раслау турында” 2009 елның 3 сентябрендәге 467 номерлы боерыгы.

5. Россия Федерациясе Мәгариф Министрлыгының “Өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында” 2018 елның 9 ноябрендәге 196 номерлы боерык

6. РФ Мәгариф һәм фән Министрлыгының “Белем бирү эшчәнлеген, электрон белем бирүне, белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда дистанцион белем бирү технологияләрен гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан куллану тәртибен раслау турында” 2017 елның 23 августындагы 816 номерлы боерык»

7. "СанПиН 2.4.4.3172 -14 "Балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында эш оештыру төзелеше, эчтәлеге һәм режимына куела торган санитария-эпидемиология таләпләре " РФ дәүләт баш санитария табибының 04.07.2014 чыккан 41 нче номерлы карары

Программаның юнәлеше – **табигый-фәнни.**

Бүгенге җәмгыятьтә укытучы алдында гаять зур бурычлар тора. Конкуренциягә сәләтле, заман таләпләреннән чыгып эш итә белә торган, рухи һәм физик яктан камил шәхес тәрбияләү – иң төп максатыбыз. Ә ул үз чиратында, туган телебезне яратучы, үз милләтенең мәдәниятен, иң күркәм йолаларын, гореф-гадәтләрен, тарихын хөрмәт итүче булырга тиеш. Зыялылык, ватанпәрвәрлек кебек сыйфатлар үзеңнең туган телеңне, аның әдәбиятын, танылган кешеләрен яхшы белгәндә генә формалаша ала. Программа түгәрәккә йөрүче укучыларны дөрес итеп сөйләшергә өйрәтү, укучыларның сөйләмен баетып, туган телләре турында күбрәк мәгълүмат бирү, мәктәп укучыларының күпкырлы үсешен тәэмин итү кебек практик мәсьәләләрне хәл итүне шарт итеп куя.

Әлеге түгәрәк программасы укучыларга үзләренең мавыктыргыч сүз дөньясын күрсәтергә мөмкинлек бирә. Бу уку эшчәнлеге нигезләре буларак чын танып белү кызыксынуларын формалаштыру өчен зур әһәмияткә ия.

Телне белү барлык уку фәннәрен уңышлы үзләштерү өчен шартлар тудыра. Сүзне яхшы белмичә, бернинди танып-белү эшчәнлеге дә мөмкин түгел. Шуңа күрә берләшмәнең дәресләрендә укучыларның телдән һәм язма телен үстерүгә, аларда тел хисе тәрбияләүгә юнәлдерелгән биремнәргә аерым игътибар бирергә кирәк. Мәктәп укучыларында сөйләм тәртибенең этик нормаларын тәрбияләү эшен көчәйтсәк, телнең укыту предметы буларак тәрбия мөмкинлекләре күбрәк гамәлгә ашырылачак.

«Күңелле татар теле» укытуның эчтәлеге һәм методлары укучыларның туган тел дәресләрендә алган ныклы белемнәрен һәм күнекмәләрен алуга һәм ныгытуга ярдәм итә, үсеш, тәрбия һәм белем бирүнең бердәмлеген тәэмин итә.

Берләшмә эшчәнлеген уңышлы үткәрү өчен төрле эш кулланыла. Уен элементлары, уеннар, дидактик һәм тарату материалы, мәкальләр һәм әйтемнәр, физкультминутлар, рифмалар, санагычлар, ребуслар, кроссвордлар, башваткычлар, тестлар, грамматик әкиятләр. Дидактик

материал күпчелек очракта шигырь формасында бирелә, бу аны җиңелрәк үзләштерергә һәм ятларга ярдәм итә.

Болар барысы да балаларга сүзнең матур дөньясын ачарга, аларны яратырга һәм туган телне тоярга өйрәтә.

Программаны үзләштерүнең планлаштырылган **нәтиҗәләре:**

Туган телне өйрәнүнең шәхси нәтиҗәләре:

- кеше аралашуның төп чарасы буларак телне белү;
- милли мәдәният күренеше буларак туган телне (татар) кабул итү;
- дөрес сөйләм һәм язма сөйләмнең кешенең индивидуаль культура күрсәткечләре булуын аңлау;
- үз сөйләмеңне күзәтү нигезендә үз-үзеңне бәяләү сәләте.

Туган телне өйрәнүнең метапредметаль нәтиҗәләре булып тора:

- уку проблемаларын чишү өчен төрле чыганакларда кирәкле мәгълүмат табу өчен телне куллана белү;
- аралашу максатларында, бурычларында, чараларында һәм шартларында ориентлаша белү;
- сөйләмнең төрле төрләрен һәм аралашу ситуацияләрен исәпкә алып, коммуникатив мәсьәләләрне (диалог, телдән монологик әйтемнәр, язма текстлар) уңышлы хәл итү өчен тиешле тел чараларын сайлый белү.

**Программаның актуальлеге:**

Телне белү барлык уку фәннәрен уңышлы үзләштерү өчен шартлар тудыра. Сүзне яхшы белмичә, бернинди танып-белү эшчәнлеге дә мөмкин түгел. Шуңа күрә берләшмәнең дәресләрендә укучыларның телдән һәм язма телен үстерүгә, аларда тел хисе тәрбияләүгә юнәлдерелгән биремнәргә аерым игътибар бирергә кирәк. Мәктәп укучыларында сөйләм тәртибенең этик нормаларын тәрбияләү эшен көчәйтсәк, телнең укыту предметы буларак тәрбия мөмкинлекләре күбрәк гамәлгә ашырылачак.

**Программаның аерылып торучы үзенчәлекләре:** Татар телен, матур әдәбиятны сөйләп кенә бала күңеленә сеңдереп булмый. Бала эшчәнлеккә үзе катнашканда гына, үз күзләре белән күреп, үз куллары белән тотып караганда гына үзе өчен ачышлар ясый һәм белмәгәннәрен бүтәннәргә җиткерә ала. Эзләнү–тикшеренү эшләре аша укучыларга туган телебезнең матурлыгын җиткерү, халкыбызның мәдәнияте, әдәбияты, сәнгате белән кызыксындыруга ирешү.

**Программаның адресаты:** 11-17 яшьлек укучылар, группада беренче уку елында 15 укучы булу яхшы.

**Программаны үзләштерү вакыты, дәресләр үткәрү режимы, периодлылыгы, дәвамлылыгы:** "Күңелле татар теле" программасы 1 елга исәпләнә. Дәресләр атнага 2 тапкыр, 2 шәр сәгатьтән 15 минутлык тәнәфес белән үткәрелә. Укыту планы буенча 144 сәгать.

**Оештыру үзенчәлекләре:** төрле яшьтәге укучылар.

Дәресләр берләшмәнең барлык катнашучылары белән дә, аерым алынган тема буенча укучылар төркеме белән дә, конкурс эшләрен, тикшеренү эшләрен, олимпиадаларга әзерләнгәндә индивидуаль консультацияләр рәвешендә дә узарга мөмкин.

Дәресләрне кирәк булганда, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасы "Азнакай шәһәре балалар иҗат үзәге" һәм Азнакай шәһәре 7 нче урта мәктәбе арасында төзелгән челтәрле элемтә турында килешү нигезендә 7 нче урта мәктәп базасында үткәрергә мөмкин.

Укыту формасы: көндезге. Программаны яки аның өлешләрен тормышка ашырганда, электрон укыту, дистанцион белем бирү технологияләрен, практик дәресләр, укучыларның өлгерешен тикшерү өчен агымдагы контроль, арадаш аттестация формаларын кулланырга мөмкин.

**Максат:** укучыларны туган телебезнең байлыгы белән тирәнтен таныштыру; иҗади сәләтләрен үстерүгә мөмкинлекләр тудыру, әхлакый сыйфатлар тәрбияләү.

Программа түбәндәге **бурычлар**ны үз эченә ала:

• уку предметы буларак туган тел белән кызыксынуны үстерү;

• туган телгә мәхәббәт тәрбияләү;

• укучыларда мөстәкыйль рәвештә туган телне белү өстендә эшләү ихтыяҗын уяту;

* укучыларның гомуми тел үсешен камилләштерү.

Укучылар эшчәнлеген оештыру түбәндәге **принципларга** нигезләнә:

* мавыктыргыч;

* фән;

* аң һәм активлык;

* күрсәтмәлелек;

* мөмкинлек;

* теорияне практика белән бәйләү;

* укучыларга шәхси караш

**2 нче бүлек Уку-укыту тематик планы**

| № | **Тема** | **Сәг. саны** | **Теория** | **Практика** | **Аттестация формасы** |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Кереш. | 6 | 6 | - | |
| 2. | Авазлар һәм хәрефләр илендә | 46 | - | 46 | Тестлар |
| 3. | Орфография белән дуслаш! | 40 | 10 | 30 | Әңгәмә, практик эш |
| 4. | “Мин дә шагыйрь, язучы” | 52 | 4 | 48 | Практик эш – презентация төзү |
| | **Барысы:** | **144** | **20** | **124** | |

## 3 нче бүлек Программаның эчтәлеге

## Программаның эчтәлеге (1 нче уку елы)

**Авазлар һәм хәрефләр илендә**

**Теория:** Авазлар һәм хәрефләр турында әкиятләр. Иҗекләр. Сүзләр. Калын сузык авазлар кергән тел шомарткычлар. Калын сузык авазлар белән табышмаклар һәм мәкальләр. Нечкә сузык авазлар кергән тел шомарткычлар.

**Практика:** Калын сузык авазлар белән фонетик күнегүләр. Авазлар белән уеннар. “Кем күбрәк? “Тылсымлы чылбыр”, “Буталган хәрефләр”, “Ахырын тап”. Авазлар белән уеннар. Тел көрмәкләндергечләр. Үртәвечләр.

**Орфография белән дуслаш!**

**Теория:** Логогрифләр. Анаграммалар. Тел шомарткычлар. Метограмма

**Практика:** Орфографик лото. Орфографик домино. Табышмак уеннар. Метаграммалар. Тел хикмәте. Викторина. Фонетик күнегүләр. Сүз эчендә сүз. Без дә яңа сүзләр ясап карыйк.

**“Мин дә шагыйрь, язучы”**

**Теория:** Якташ язучыларның тормыш юлы, иҗаты белән танышу. Якташ язучыларның иҗатлары буенча телдән журнал. Күренекле шәхесләр: язучылар, шагыйрьләр.

**Практика:** Хикәя, әкият язарга өйрәнү. Укучылар язган хикәя, әкиятләрне тикшерү. Туган җирем – татар телле Татарстан (Туган тел турында...). Туган төбәк, туган җир, туган телебез турында иҗади эшләр дәресе. “Газиз дә син, кадерле дә, әй Туган телем!”- “Тамчы-шоу” уены. Эзләнү – тикшеренү эшләре. Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау.

## 4 нче бүлек

## Планлаштырылган нәтиҗәләр

Бу программа балаларның түгәрәк эшчәнлеге белән кызыксынуларын арттырыр, активлыкларын үстерер, тәрбия эшендәге эзлеклелек һәм дәвамчанлыкны тәэмин итәр, белем дәрәҗәләрен, иҗади сәләтләрен үстерергә этәргеч бирер. Программаның һәр бүлегендә алынган максатчан юнәлешле эшләр укучыларга туган тел белән кызыксыну, белемнәрен арттыру, эшне оештыру өчен һәм киләчәк тормышларында юнәлеш бирер өчен мөмкинлекләр бирер. Түгәрәктә укучыларның һәр адымында үз җаваплылыгын тоеп, туган теле белән горурланып, телнең нечкәлекләрен өйрәнү, мөстәкыйльлек, сәләте буенча иҗади хезмәтен оештырырга, әхлакый, сәламәт, туган телен яратучы, саклаучы игелекле шәхес булып үсәргә, баланың үз мөмкинлекләрен гамәлгә ашыруына ирешергә тәрбияви юнәлеш бирә. Шунлыктан бу программа белән эшләү күпкә уңайлы һәм нәтиҗәле булачак. Чөнки программа балаларга аңлаешлы, көчләре җитәрдәй эшләрне үз эченә ала. Кыскасы, укучы үзен чын гражданин, җәмгыятебез өчен үзен кирәкле, файдалы шәхес, горур милләтле татар баласы итеп тоячак. Туган телен, халкын яратачак, үзе башкарып чыккан гамәлләре, иҗади эшләре белән горурланачак, биеклекләр яулаячак.

**Беренче уку елында укучыларда формалаштырылырга тиешле белем:**

«Күңелле татар теле» укытуның эчтәлеге һәм методлары укучыларның туган тел дәресләрендә алган ныклы белемнәрен һәм күнекмәләрен системага салуга һәм ныгытуга ярдәм итә, үсеш, тәрбия һәм белем бирүнең бердәмлеген тәэмин итә.

**Беренче уку елы азагына формалаштырылырга тиешле күнекмәләр:**

- укучыларда эзләнү-тикшеренү, материалны системага сала белү;
- материалны анализлый, системалаштыра, гомумиләштереп, нәтиҗәләр ясый белү;

- үз халкының тел байлыгын өйрәнү, аны үстерү һәм саклау өчен үзләреннән өлеш кертә белү

## 5 нче бүлек

## Программаны тормышка ашыруның оештыру-педагогик шартлары

**Тормышка ашыру шартлары:** таләпләргә туры килеп яктыртылган укыту кабинеты, укытучы өстәле белән урындыгы, укучылар өчен өстәлләр белән урындыклар, класс тактасы, ноутбук, “Күңелле татар теле” өстәмә гомуми белем бирү гомуми үсеш программасы, югары педагогик белемле педагог, мультимедиа чаралары,

**Методик материал**: “Күңелле татар теле” өстәмә гомуми белем бирү гомуми үсеш программасы, китаплар, әдәби китаплар, видеоязмалар, журналлар. **Укыту алымнары**: күрсәтмә практик, өлешчә-эзләнү, аңлатма-иллюстратив, эзләнүле, уен, проект төзү.

**Белем бирү процессын оештыру формалары**: индивидуаль-төркемнәр белән эш һәм төркемнәрдә эш.

**Дәресләрне үткәрү формалары һәм төрләре:** практик, мөстәкыйль һәм иҗади эшләр, интеллектуаль уеннар, эзләнү-тикшеренү эшләре, әдәби кичәләр, әңгәмә, индивидуаль консультацияләр, түгәрәк өстәл, дәрес-презентация, викторина, КВН, сәяхәт-дәрес, бәйгеләр, укучыларның әдәбият белән мөстәкыйль эше.

Укучыларда кызыксыну уяту өчен һәр дәрестә иҗадилык һәм эзләнү элементларын кертү. Теоретик һәм практик дәресләрне чиратлаштыру.

**Педагогик технологияләр**:

- үстерелешле укыту;
- хезмәттәшлеккә корылган укыту технологиясе;
- коммуникатив технологияләр;
- проблемалы һәм өлешчә эзләнү технологияләре;

Педагогик технологияләр һәм методларны сайлау укучының шәхси сыйфатлары һәм универсаль уку күнекмәләрен үстерү максатыннан укытуны дифференциальләштерү һәм индивидуальләштерү кирәклегеннән чыгып билгеләнде.

**Дәресләрнең алгоритмы.** Укыту дәресенең алгоритмы-этаплар саны аның тибына һәм белем бирү процессының урынына, шулай ук педагог сайлаган урынга, үткәрү формасына бәйле. Әлеге программа кысаларында нигездә уку дәресенең 10 этабы кулланылырга мөмкин:

Оештыру этабы;

Тикшерү этабы;

Әзерлек этабы;

Белемнәрне актуальләштерү этабы;

Яңа материал буенча эш этабы;

Алынган белемнәрне, күнекмәләрен беренчел беркетү этабы,

Өйрәнелгән материалны кабатлау этабы;

Үткән материалны гомумиләштерү этабы;

Яңа белемнәрне, күнекмәләрне ныгыту этабы;

Физкультминутка яки релаксация этабы;

Контроль этап;

Йомгаклау этабы;

Рефлексия этабы;

Мәгълүмат этабы

## 6 нчы бүлек

## Аттестацияләү формалары/контроль һәм бәяләү материаллары

**Аттестация формалары**: күзәтү, практик эш, мөстәкыйль эш, бәйге, әдәби – музыкаль кичә.

**Укыту нәтиҗәләре** видеоязма, иҗади эш, диплом, фотосурәт, фоторепортаж, презентация, эзләнү эше, проект яклау, әзер эш аша билгеләнә.

Укыту нәтиҗәләрен фәнни-практик конференциядә катнашу, иҗади эш яклауда, күргәзмәдә, конкурста, бәйрәмдә күреп була.

**Аттестация материаллары** кушымтада бирелгән.

## 7 нче бүлек Әдәбият исемлеге

### Программа төзү өчен кулланган әдәбият исемлеге:

1. “Уйный-уйный укыйбыз". Төзүче автор Г. Гәрәева. Казан. “Яңалиф” нәшрияты, 2007.

2. “Хикмәтле дә, бизәкле дә Туган тел”. Ф.С. Сафиуллина, Г. Б. Ибраһимова. Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 1998.

### Педагог өчен әдәбият исемлеге:

1. Әбдрәхимова Я. Х. Татар теленнән дидактик материаллар. – К., 2004.

2. Вагыйзов С.Г. Кызыклы грамматика. – Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2002.

3. Валиев. З. В. Эш кәгазьләре үрнәкләре. – К., 1999.

4. Галимуллин Ф. Г. Укучыларны сәнгатьле укырга өйрәтү. – К., 1988.

5. Максимов Н. В. Татар теленнән тестлар. – К., 2002.

6.”Мәгариф”журналлары

В данном документе пронумеровано, прошнуровано и скреплено печатью
15(пятнадцать) листов
Директор Хасанова Р.М.
Подпись: